


ISSN 0868-4545

Сабантуй купере





Бәйге тәмам... җиңүчеләрне котлыйбыз!

Ошбу ел башында (2 (203)-2007) «Салават күпере» журналханәсе «Куяннар – агач башында...» дигән яңа бәйге игълан иткән иде. Менә, ниһаять, конкурска нәтиҗә ясар вакыт та җитте. Иң әүвәл бәйгедә укучыларыбызның бик актив катнашуын ассызыклап үтәргә кирәк: хәтта кайбер балалар конкурска әкиятнең дәвамын берничә вариантта язып җибәрделәр. Шундыйлардан бертуган Римма һәм Марат Шәеховларның (Азнакай) һәм Айрат Җәләлетдиновның (Тәтеш, Түбән Тархан) исем-фамилияләрен искә төшереп үтәбез. Алар редакциянең махсус дипломнарына лаек булдылар. Шундый ук дипломнарга Балык Бистәсе районы Түбән Тегерләнлек мәктәбе укучысы Алсу Гарифуллина, Балтач районы Таузар башлангыч мәктәбе укучылары Рәсим Габдрахманов, Айсылу Галиева, Айнур Нәбиев һәм Рөстәм Гыйззәтуллин да ия булды. Журналханә Зөлфия Гарифуллинага (Балык Бистәсе, Күгәрчен), Илназ


кошлар үз телләрен югалтмаган, хәтта төлке дә үз телендә сөйләшә икән ди.
Барысы да бик бәхетле булган, һәммәсе дә рәхәт яшәгән ди. Үзенең туган телендә сөйләшкәч, әлбәттә, бәхетле булалар инде.
Менә берзаман бу урманга бик усал, дәһшәтле Әтәч исемле аю килеп чыккан. Аю Әтәч беркемнең дә телен аңламаган, бер җәнлек белән дә аралашып, сөйләшеп китә алмый икән ди тагы. Аю Әтәчнең моңа бик нык ачуы килгән һәм ул катгый итеп акырып әйткән: „Моннан соң мин аңламаган



Вәлиев һәм Нурзилә Хәлиловага (Чистай, Мөслим) үзенең истәлекле бүләкләрен җибәрәчәк.

Мәртәбәле жюри, үзара киңәшләшкәннән соң, әлеге укучыларыбызны җиңүчеләр дип тапты:

Беренче урын – **Ләйсән һәм Булат МӨХӘРЛӘМОВЛАР** *(Биектау, Зур Битаман)*. Алар әкиятнең дәвамын, рәсемнәр белән бизәп, китапчык итеп җибәргәннәр (кызганыч ки, әкият бик озын язылган булуы сәбәпле, журналда урын ала алмады).

Икенче урын – **Азат АХУНОВ** *(Яр Чаллы)*. «Аю Әппәс белән Батыр» һәм «Ярдәм сорап – Президентка» дигән әкият-дәвамнары өчен.

Өченче урын – **Диана ФАТЫЙХОВА** *(Мөслим, Иске Карамалы)*.

Алдан хәбәр иткәнебезчә, җиңүчеләр уен компьютеры (I урын), велосипед (II урын) һәм видеоплейер (III урын) белән бүләкләнә.

ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ КОТЛЫЙБЫЗ!
УҢЫШЛАР СЕЗГӘ, ДУСЛАР!

Ошбу биттәге рәсемнәр Ләйсән һәм Булат МӨХӘРЛӘМОВЛАРның китапчыгыннан алынды.

(Ахыры 22-23 битләрдә.)

Рөстәм Мингалим шигырьләре



Шагыйрь Абыйга 70 яшь тулды. Котлыйбыз!

Миннән сора

Ник елмаям,
ник бүген елмаям мин һаман?
Мин янымда әткәм барга куанам.
Әткәм ник елмая?
Ул ник куанган?
Белмисеңме?
Янында мин булганга!
Һәм Кояш бүген көнозын
ни өчен шулай куана?
Ник һаман авыз ера?
Белмисеңме?
Миннән сора!
Кояшның
кавын хәтле
малае бар!
Күзе аның – борчак хәтле,
борыны – кызыл борыч хәтле,
ул Кояш артына качып тора.



Хәтерлә әле

Песи авызында
Күрдең син аны.
Хәтерлә әле,
ул ни булыр?
Һәм эт авызында
Күрдең син аны.
Хәтерлә әле,
ул ни булыр?
Син хәтерләсәң,
хәтерләмәсәң дә,
ул гел булыр.
Аның исеме,
исеме аның –
тел булыр.

«Күк-күі»,
яки урманда

Кечкенә куян
көн үзәгендә –
йоклый урманда,
агач төбендә...
Бу бәби куян,
һаман уянмый.
Кошлар уята
бәби куянны.
– Чү, чү-чү! Чүти-чүти!
– Юти-юти!
– Итю-итю!
– Тюр-р-р, тюр-р-р!
– Күк-күі! Күк-күі! Күк-күі!

Бу бәби куян,
йоклый ул күптән.
Ул уянганны
әнкәсе көтә...
Тыңлап кошларны,
аңлап сүзләрен,
кечкенә куян –
ача күзләрен.
– Чү, чү-чү! Чүти-чүти!
– Юти-юти!
– Итю-итю!
– Тюр-р-р, тюр-р-р!
– Күк-күі! Күк-күі! Күк-күі!

Алма төшкән

Алма төшкән,
Тәгәрәп киткән.
Аны мәче
Куып җиткән.
– Кая киттең,
Кызыл алма? –
Дип сораган
Мәче аннан.
Тәгәрәүче
Эндәшмәгән,
Тәгәрәгән,
Алга киткән.
Һәм ул үзе –
Алма түгел,
Кызыл йомгак
Булган икән.

Рәссам Алла АЙСИНА



Рөстәм МИНГАЛИМ

Сагындыңмы, улым...

Бер малайны шәһәрдә калырга, бераз кунак булырга кыстадылар.

– Каласыңмы? – диде әтисе. – Мин сине килеп алырмын, – диде.

Малай беразга шәһәрдә калырга булды. Чөнки ул монда бергә уйнарлык дуслар да очратты. Әтисе дә аның үз сүзен үти торган кеше. Ул малайны килеп алачак, әлбәттә.

Шулаен шулай да... Инде малай – ул шәһәрдә озаграк торды шикелле — тизрәк әтисенең килүен көтә.

Әтисенең килүен көтеп, гел боегып кына тормый ул торуын. Гел кунак булып, өстәл янында сыйланып кына да утырмый. Яңа дуслары белән уйный. Якындагы кибеткә ипигә йөри.

Өйдә әле ипи бетмәгән чаклар, ипи сатып алу кирәкмәгән көннәр дә була. Андый көннәрдә дә малай ипи кибетенә керә: бер керә, ике керә. Кичә, өйгә әле ипи кирәкмәсә дә, кесәсендә акчасы булмаса да, ул кибеткә өч мәртәбә керде... Шулай керә дә киштәләрдәге түгәрәк, шакмак, ак, кара ипиләрне карап йөри.

– Сатып алмый. Нишләп йөри бу малай? Әллә ипи чәлдерергә йөриме? – дип уйлый кибетче апа.

Чәлдерергә йөрми ул. Нишләп йөргәнен малай үзе яхшы белә. Аңа шулай йөрү рәхәт. Чөнки шәһәрдәге ипи кибетеннән авыл исе килә.

Бүген малай кибеттән ике ипи сатып алды. Кайтып керсә, ни күрсен – өйдә аны әтисе каршылады!

– Сагындыңмы, улым, авылны? Иртәгә кайтабыз! – ди.

Малай шатлыгыннан сүзсез торды. Аннан әтисен кочаклап алды.





Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

Төймә

Ишегалдындагы комлыкта Айгөл өй ясап уйный. Тугыз катлы йорт кыреннан кояшның әле мыегы гына күренә. Ком юеш. Айгөл тырышып-тырышып өйнең диварларын өя. Кояш сыярлык өй булачак!

Айгөл янына күршесе Ильяс килде. Эндәшмичә генә кызга ялтырап торган төймә сузды. Бүләк! Кызлар бүләк биргәнне ярата.

Ләкин Айгөл борынын әре генә тартып куйды да:

– Мин төймә яратмыйм, – диде.

Ильяс аптырады:

– Нәрсә яратасың?

– Кояшны! Шуны алып бир, мин аны бу өйгә ябармын.

Өй кырыенда инде кояшның сакалы да күренә иде.

Ильяс шактый гына Айгөл янында басып торды әле. Инде тугыз катлы йорттан шактый өскә үрләгән кояш аңа күзен кысты. «Күңелеңне төшермә», – дигән сыман...


Ильяс учындагы ялтырап торган төймәне бик еракка ыргытты да өенә кереп китте.

Шуны гына көткәндәй җил исеп куйды, итәкләрен җилфердәтеп күктә кара болыт шуышты. Яңгыр ява башлады. Кояш югалды.

Айгөл ышыкка йөгерде. Кереп китәр алдыннан комлыкка борылып карады ул. Аның кояш сыярлык өе ишелеп төшкән иде инде.

Рузилә МӘХӘММӘТОВА

Бичуралы әкият



– Сәлам, Сәлимә!

– Кем син?

– Мин – Бичура.

– Син безгә кунакка килдеңме?

– Юк, мин биредә – бу фатирда яшим.

– Алдашма, биредә мин яшим.

– Мин алдаша белмим шул.

Шулчак Сәлимәнең әнисе уянды:

– Кызым, син уяндыңмыни? Нәрсә булды?

– Бичура, Бичура, син кайда?..

– Елама инде, кызым. Кемне югалттың? Йә беттеме, балакаем. Әйдә, әәәәәә итәбез...

Бичура икенче төнне дә килде, өченче төнне дә... Тик төн саен сөйләшсә дә, үзе күренмәде. Кызның ялынып ялваруын да ишетмәмешкә салышты. Үзсүзләнеп гел үз дигәнен эшләтергә өйрәнгән Сәлимә хәйләләп карарга уйлады: Бичурага үпкәләгән булып кыланды. Дусты белән сөйләшмәде. Кыен булса да, түзде. Көннәрдән бер көнне Бичура авыр сулап:

– Бик күренер идем, юк бит мин, – диде.

– Ничек инде – «юк»?

– Күзем бар, сүзем бар... үзем юк!

– Ничек инде?

– Күренмим мин.

– Нигә?

– Мин бу дөньяда бик озак яшәдем. Яши-яши гәүдәм тузды, җаным гына сакланып калды.

– Сиңа яңа гәүдә тегәргә кирәк икән...

– Бик кирәк тә бит... син әле кечкенә шул, әнә тота белмисең.

– Мин тиздән үсәм. Әни әйтте: «Кызым дәү үсә», – диде.

– Тик син үскәч мине онытачаксың.

– Онытмыйм.

– И Сәлимә, минем белән балалар гына сөйләшә, алар гына күрә шул.

– Кызым, ни булды? Йә тынычлан. – Тагын әнисе уянды. – Ямьсез төшләр керәме әллә?

Юк шул, аңламый әнисе Сәлимәне, аңларга да теләми шикелле.

Икенче көнне Сәлимәләргә күрше бабай керде.

– Исәнмесез, Әзһәр абый. Узыгыз! – дип каршылады әнисе үзләренең күршесе, халык артисты Әзһәр Шакировны. Әзһәр абый Сәлимәгә уенчыклар алып кергән иде. Машина да бар, синтезатор да... тагын зур сакаллы, кызыл корсаклы, түгәрәк борынлы, ак чәчле... нәни курчак, дөресрәге, әллә нинди бер җан иясе. Сәлимә аптырап карап торды да, синтезаторга үрелде. Шулчак теге «курчак» күз кысып куйды, ул да булмады, сакалын мәзәк кенә селкетеп, биеп китте.

– Әни, карале.

– Әйе, кызым, бу Бичурага охшаган икән. Әзһәр абый заманында «Бичура» дигән спектакльдә уйнаган иде. Кызым, әйдә, Бичураны стенага элеп куябыз...

Нигә әнисе Сәлимәнең дустын элеп куймакчы була соң? Нигә ул Бичураның биюен күрми? Бичура: «Мине өлкәннәр күрми-ишетми», – дип дөрес әйттеме икән? Ә күрше бабай кайдан белгән соң Бичурага гәүдә кирәклеген?

– Артистлар алар балалар кебек, Сәлимә. Алар бала күңелле булганга артист бит инде... – дип дәште Сәлимәнең нәни дусты.

– Бичура, хәзер син минем янга көндез дә килерсеңме?

– Дәү үсү өчен төнлә йокларга кирәк, Сәлимә. Без көндез уйнарбыз, яме.

...Сәлимәнең әнисе телефоннан сөйләшә:

– Аллага шөкер, Сәлимә төннәрен тыныч йоклый башлады. Көне буе сакаллы курчагын күтәреп йөри. Кызык инде бу балалар: әллә күпме уенчыгы бар, матур курчаклары... ә ул Бичура белән уйный.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





Равил ФӘЙЗУЛЛИН шигырьләре



Алтын балык түгел, гади балык сөйләде бик гасабиланып...

«Без яшәгән илләрдә –
елгаларда, күлләрдә –
су асты катларында,
бормалы чатларында,
комлы уемнарында,
таллык куеннарында,
караңгы төпкелләрдә,
мүкләрдә һәм ләмнәрдә
каян килгән нәрсәләр бу:
галошлар, итекләр,
күгәргән үтүкләр,
кәчтрүл-чиләкләр,
иләкләр, көрәкләр,
буяулар, цементлар,
ташландык уенчыклар,
кирпечләр-ярчыклар,
целлофан капчыклар...

Болар безнең Су иленә
каян килгән?
Нигә килгән?
...Болар барсы өстән
килгән –
Кеше дигән көчтән килгән!
Уйлап куям:
җир өстендә яшәүчеләр
эчкән чишмәләренә дә
тирес аудара микән?
Ашый торган ашларына
мунчала сала микән?
Йоклый торган
түшәкләрен
дегетләп ята микән?
Балалары бишегенә
тимер-таш ата микән?
Шулайдыр дим, юкса алар
Табигатьне аңламаслык
туңга әйләнмәс иде!
Җир-Су рәнҗер дәрәҗәдә
үк вәхшәтләнмәс иде...»
...Шулай диде дә
балыгым суга чумды.
Мин ярда калдым да,
уйга чумдым.

Без – балта осталары

Кемгә – койма!
Кемгә – капка!
Булсын гына
яңа кадак,
яңа такта!

Кемгә – бура!
Кемгә – колга!
Булса кулда
яхшы балта,
үткен пычкы
һәм дә теләк:
кемгә – келәт,
кемгә – көрәк!
Тагын кемгә
нәрсә кирәк?

Беләктә – көч!
Кулда – чүкеч!
Кемгә – шкаф!
Кемгә – киштә!
Күңел салгач
сөйгән эшкә,
туйдырмый ул
агач тәмен
тою һич тә!
Килә бирсен
урман исе
иртә-кич тә!

Агач җаны
яши алса
без ясаган
җиһазларда,
без төзегән
биналарда –
сөенәбез
без шуңарга!
Урман булып,
шатлык шаулый
безнең җанда!

Күңелдә дәрт,
кулда җегәр,
йөрткән чакта –
кемгә – сандык,
кемгә – тартма!..
Булсын гына
яңа кадак,
яңа такта!

Эшләребез
балкып торсын
Туган якта!
Искә алып,
яхшы сүзләр
сөйләсеннәр
безнең хакта!

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





Пилмән белән Тилгән

Бүген безгә әбәткә
Әни пешергән пилмән.
Пилмән исе җил белән
Урманга килеп кергән.

Уяткан ис карганы,
Уяткан ис тилгәнне...
Тилгән очып килгән дә
Чәлдергән бер пилмәнне.

Тилгән очып киткәнне
Күреп калдым мин читтән.
Тагын пилмән пешерсәк,
Яныннан мин һич китмәм.

Ренат АЛИЕВ, 10 яшь.
Әлки, Базарлы Матак.



Алмир КӘРАМОВ, 11 яшь.
Саба, Тимершык.

Туган авылым

Туган авыл бик якын ул –
Шунда уйнап үстең син.
Авылыңның чишмәсеннән
Татлы сулар эчтең син.

Авылыңда ишеттең син
Әнкәңнең бишек җырын.
Хозурланып тыңладың син
Иртәнге кошлар моңын.

Әгәр китсәң син еракка,
Авылыңнан аерылып.
Авылыңны бик сагынып,
Карарсың бер кайрылып.

Илүзә МОРТАЗИНА, 11 яшь.
Ютазы, Бәйрәкә-Тамак.



Раил СӘФӘРГАЛИЕВ, 10 яшь.
Балык Бистәсе, Котлы Бөкәш.



Айвар САДЫЙКОВ, 13 яшь.
Арча, Алан.



Азат СӘМИГУЛЛИН, 8 яшь.
Саба, Өтернәс.

Чикерткә ник яшел
һәм ник ерак сикерә?

(Әкият)

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер кара чикерткә, ул ялкау һәм көчсез булган. Чикерткәне күргәч, бөтен бөҗәк, бөтен хайван аннан көлгән. Беркөнне яшел чирәмле аланда чикерткәне бер кош күргән дә артыннан килеп, ашамакчы булган. Чикерткә аны күреп алган, курку генә түгел, куркуыннан яшел төскә кергән һәм бик еракка сикергән. Шулай итеп ул дошманнарыннан кача алуын аңлаган. Менә хәзер дә алар яшел һәм ерак сикерә торган булып яшиләр.

Рушан СӘЛӘХОВ, 9 яшь.
Актаныш, Чалманарат.



Дана ШӘФЕЕВА, 6 яшь.
Казан.



Рафил ВӘЛИЕВ, 10 яшь.
Этнә, Ары.

Беләсем килә!

Нәкыйп КАШТАНОВ

Тәвә кошы



Розаның әтисе Африкада сәяхәттә йөреп кайтты. Ул саваннада күп төрле кыргый җанварлар: арысланнар, антилопалар, жирафлар, бүреләр, гиеналар күргән икән. Шуларны күзәтеп йөргәндә, тәвә кошын да очраткан. Куркак икән тәвә кошы, шундык йөгереп качкан, койрыгыннан бик матур бер каурый төшеп калган. Менә шул каурыйны Розага алып кайткан әтисе.

Каурый Розага бик ошады. Тәвә кошы хакында күбрәк беләсе килде.

– Ниндиерәк кош соң ул тәвә, якыннан күрдеңме аны, әтием? – дип кызыксынды.

– Якыннан күрдем, кызым. Ул иң зур, иң көчле, иң җитез кош. Тик оча гына белми. Буе да биек аның, дошманнарын ерактан ук күреп ала.

– Әтием, ә ни өчен ул кош оча белми икән, ә?

– Мин дә, кызым, шул хакта уйлаган идем. Сәяхәттә йөргәндә бер аксакалдан сорадым. «Тәвә кошына очарга кирәкми дә, – диде ул. – Тәңре аңа барсын да җитәрлек биргән. Ә кем биргәнгә разый түгел, ул булганыннан да колак кага...» Менә шул, кызым. Ә каурый сиңа хикмәтле тәвә кошыннан бер истәлек булсын.



Тургай һәм тартар

Арыш кыры читендә тургай белән тартар очрашкан.

– Әй күрше, тартар дус, – дигән тургай, – карап-карап торам да, син бер дә күзгә күренми яшисең. Сукмакларың биек арыш арасында, йөргәндә дә башыңны иеп кенә йөрисең. Әллә берәр кайгың бармы синең?

– Хәлемне белгәнгә рәхмәт, – дигән тартар. – Аллага шөкер, кайгым юк. Җирдән орлык эзләгәнгә башымны гел иеп йөрим мин.

– Син ара-тирә күккә дә карап алгала, тартар. Күкләр нинди биек, нинди зәңгәр әнә. Мин шул күкләргә нокта булып кына күренерлек итеп күтәреләм дә рәхәтләнеп сайрыйм. Мине ишетмәгән кеше юктыр, мөгаен. Исемемне хәтта җырларга да кушып җырлыйлар. Ә синең барлыгыңны беркем дә белми, тартар.

– Һәркем үзенчә яши инде: кемдер сайрый, кемдер орлык эзли. Мине белмиләр дип бер дә кайгырмыйм анысы. Бәлки белмәүләре яхшырактыр да әле...

Тургай тартарның сүзләрен тыңлап та бетермәстән, канатларын фырылдатып, болытларга кадәр күтәрелде дә: «Дөнья матур, дөнья киң...» дип сайрый башлады.

Тартар күтәрелеп тә карамады. Күкләргә орлык сипсәләр, бәлки, карар иде дә... Хәер, каян белсен ул күккә орлык сипкәннәрен. Аның өчен гомердә хет бер тапкыр башны югары чөяргә кирәк ләбаса...

Рәссам Диләрә НӘҮРҮЗОВА




Венер, 10 ай

– Күп «йөрелде» – арылды:
Бераз хәл алыйм әле...
Тагын ишеккә кадәр
Шуышып барыйм әле!

Кукмара, Каенсар.




Әлфис, 2 яшь 1 ай

– Их, дусларым, сезнең белән
Уйнаулары күңелле!
Аю, нишләп бик моңсу син? –
Әллә шулай түгелме?!

Яңа Чишмә, Чаллы Башы.


Азалия, 1 яшь

– Мин бүген бик итагатьле,
Мин бүген бик тыйнак ла...
Өйдә шукланырмын, хәзер
Мин аюда кунакта!

Казан.


Булат, 6 ай

– Берәү, икәү, өчәү, дүртәү... –
Исәбе юк мендәрнең...
Мендәр санап, өскә карап,
Җырлап ятам көн дә мин!

Апас.


Нәргизә, 6 яшь
Фәридә, 4 яшь

– Бертуктаусыз эштә без –
Чәй ясыйбыз кич-иртә:
Эссе җәйдә тәмләп кенә
Чәй эчүгә ни җитә!

Кукмара, Вахит.




– Сеңлем белән икәү бергә
Уйлаштык та килештек:
Матур киемнәрне киеп,
Сурәткә бергә төштек.

Әлмәт, Колшәрип.



– Бигрәк сәер бу кызый:
«Сәлам!» – дисәм дә, елый.
«Сине генә яратам!» дип,
Чәчәк бирсәм дә елый...

Арча, Кылачы.



– Алдымда - «Конёк-горбунок»,
Аяклар ике якта...
Әни сурәткә төшергән
Мин уйга чумган чакта.

Саба, Түкәл.



– Һинд кызлары чибәр була,
Мин алардан да матур.
Көне буе көтәм инде –
Килер микән бер батыр?!

Яшел Үзән, Акъегет.



– Әллү, әллү! Җанкисәгем,
Сагындым бит үзеңне...
Биш минуттан килеп җитәм,
Бетте тәмам түземем!

Чистай, Бахта.

Ленар ШӘЕХ

Мин бүген...

Сары,
Сары, сап-сары
Күк тавык чебиләре...
– Үлән йолкып, – диде әни, –
Кулларым чебиләде!..

Соры,
Соры, соп-соры
Бабайның куяннары...
Бүген урманга барганда
Энем бик куянланды...

Кара,
Кара, кап-кара
Әбинең кәҗәләре...
– Өстеңә ки, салкын! – дигәч,
Сеңлем нык кәҗәләнде...

Ап-ак,
Ап-ак, ак кына
Дустымның песиләре...
Бүген туган көне булгач,
Абыем песиләнде...

Мин генә берни кылмадым,
Мин бүген... кешеләндем!

Ялкау

Үрдәк әйтә: «Бак-бак, ди,
Бирегез тагарак, ди.
Рәхәтләнеп су керим,
Авыз белән су көрим...»

Тавык әйтә: «Кыт-кытак,
Төзегез миңа кетәк.
Күп йомырка салырмын,
Чебиләр чыгарырмын».

Сыер әйтә: «Му-му, ди,
Кертегез печән, су, ди.
Күп итеп сөт бирермен,
Ак май ташып йөрермен...»

Марат әйтә: «Карбыз, ди,
Бирегез сез сагыз, ди...»
Тәмле кәнфит, тәмле су –
Нәрсә була инде бу?..

Елый-елый сорый ул,
Бүре кебек улый ул.
Таң калган тавык көлә:
«Бу нәрсә эшли белә?..»

Маэмай әйтә: «Хау-хау, ди,
Безнең Марат ялкау, ди...»

МӨҖӘҺИТ

Корал эшли, мин мактанам

Табышмаклар

Тешлим дә
Суырам.
Йә тешләп
Өзәм мин.
Тик ятсам – тутыгам,
Ә эшкә түзәм мин.
(Келәшчә)

Тешләремнең исәбе юк,
Утын кисәм, он ясыйм.
Егет булсаң, кадерне бел,
Мине читкә куйма син.
(Пычкы)

Гомер буе
Сугар өчен,
Мине уйлап тапканнар.
Нигә «суккыч» диеп түгел,
Башка исем такканнар?
(Чүкеч)

Бар очым,
Бар түбәм.
Сугалар –
Мин түзәм.
Кайчакта
Кәпрәям:
Тутыгам,
Кәкрәям.
(Кадак)

Шак та шок,
Шак та шок
Тукмыйлар үземне.
Мин эшлим,
Мин тишәм,
Мин шундый түземле.
(Өтерге)

Хезмәтем бик кечкенә,
Кирәк бары көч кенә.
Менә шушы тактаны
Мине бор да тиш кенә.
(Борау)

Рәссам
Светлана ПРИВИНА







Юлларда сак бул, бала!







Жәй үтте. Гел шатлык-куаныч белән генә узмады бу җәй дә. Татарстандагы күп кенә гаиләләрне кайгы-хәсрәтле дә итте ул. 2007 елның биш аенда гына да республикада балалар белән бәйле 239 юл һәлакәте теркәлгән иде. Шуларда 249 бала төрле тән җәрәхәтләре алган, 20бала үлгән. Июнь аенда гына да 7 бала һәлак булган. Казан шәһәре Совет районының 399 санлы «Тургай» балалар бакчасында (мөдире - Л.М.Моргалева) юл хәрәкәте иминлеге хезмәткәрләре һәм журналистлар катнашында узган зур киңәшмәдә юл фаҗигаләре, аларга китергән сәбәпләр хакында җитди сөйләшү булды. Әлеге киңәшмәнең ошбу балалар бакчасында үтүе очраклы түгел. Бирелә юл йөрү кагыйдәләренә аеруча игътибар бирәләр. Бакчага Татарстан Республикасының ГИБДД идарәсе, идарәнең юл хәрәкәте иминлеге фонды (директоры – А.Н.Сахаров) зур ярдәм күрсәтеп тора икән. Фонд булышлыгы белән, шулай ук тәрбиячеләр ярдәме белән балалар үзләре яшәгән Азино бистәсенең макетын төзегәннәр. Махсус автобүлмәләрдә балалар юл йөрү билгеләрен, кагыйдәләрен бик теләп өйрәнәләр. Башкалабызда мондый күркәм эш алып баручы балалар бакчалары, шөкер, бер «Тургай» гына түгел икән әле. «Тургай» белән без байтак еллар инде тыгыз элемтәдә торабыз. Бирелә юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтүгә зур әһәмият бирелә. Нәтиҗәсе булыр дип ышанабыз», – диде Татарстан Республикасының ГИБДД идарәсе җитәкчесе Рифкать Нургали улы Миңнеханов. Сүзен йомгаклап: «Балаларның иминлеген өлкәннәр генә саклый ала. Игътибарлы булыйк», – дип янә бер кат искәртте ул.

Хөрмәтле әти-әниләр!
Кадерле балалар!
Юл йөргәндә, зинһар, сак булыгыз!
Имин яшәгез.





«Куяннар – агач башында...»

«Салават күпере»нең ярдәме

Менә бервакыт урманда бик көчле яңгыр яуган. Бар дөньяны дер селкетеп күк күкрәгән, яшен яшьнәгән. Урман халкы куркудан яшел аландагы меңъяшәр имән астына яшеренгән. Хәтта үзен иң батыр дип санаган Аю Әппәс тә дер калтыраган.

Яңгыр чиләкләп койган. Бераздан ул туктаган. Күк йөзендә ялтырап кояш чыккан. Җиде төсен балкытып, салават күпере хасил булган.

Аю Әппәс, исе китеп, аңа сокланып карап торган. Тик, кызганыч, салават күпере бераз торгач, урманда яшәүчеләргә дәрт һәм яшәү көче биреп, әкренләп юкка чыккан. Аю моны бик авыр кичергән. «Кайтарыгыз аны кабат!» – дип үкереп җибәргән.

Урманда яшәүчеләр барысы да борчуга калганнар. Киңәшләшеп, Әппәскә «Салават күпере» журналын яздырырга булганнар. «Ул да шундый ук якты, матур! – дигәннәр алар. – Иң мөһиме – ел буе сөендереп торачак!» – дигәннәр. Шулай эшләгәннәр дә.

Аю, әлбәттә инде, бик-бик куанган. Күпмедер вакыт үткәч, кырыс законнарын да йомшарткан хәтта. Сез «Ни өчен икән?» дип уйлап куйгансыздыр, мөгаен. Сәбәбе шул: «Салават күпере» тәрбияви үзлеккә дә ия. Әнә, Әппәс кадәр Әппәсне дә дөрес юлга чыгарган, матурлыкны күрә белергә өйрәткән. Аю Әппәс үзен генә яратмыйча, башкаларга да хөрмәт белән карый башлаган.

Римма ШӘЕХОВА, 14 яшь.
Азнакай.

Батыр керпе

Аю Әппәстән куркып, керпеләр җир астына качканнар. Кояш җитмәү сәбәпле, аларның әниләре коела башлаган. Шул хәлне күргәч, бер керпе дусларына: «Ни өчен без Әппәстән курыкырга тиеш? Нәрсәгә без Әппәснең телен өйрәнергә тиеш? Аның аркасында безнең энәләребез коела һәм без телебезне онытабыз. Җитте, бүген аңа буйсынмыйбыз!» – дигән.

Кич... Әппәс йокыга талган. Җәнлекләр Изге Ут янына җыелганнар. Керпеләр үзләренең фикерләрен әйткәннәр. Җәнлекләр алар белән килешкәннәр.

Иртә... Әппәс каты тавыш ишетеп уянган. Торган да, шундый хәл күргән: бөтенесе дә үз телендә сөйләшә икән. Баштан Әппәс нык итеп үкергән, аннары улый-улый Аюлар урманына йөгереп киткән. Шуннан соң җәнлекләр тату һәм бәхетле яшәгәннәр.

Азат ФӘСАХОВ, 9 яшь.
Түбән Кама.

Ябалак һәм Аю Әппәс

Кошлар үз туган телләрендә сайрауларын дәвам иткәннәр икән, ди. Алар иртә таңда да, көндез һәм кичен дә, агач башларына кунып, берсеннән-берсе матур җырлар башкаралар икән. Тора-бара Аю Әппәс тә аларның җырларына күнеккән, хәтта ярата башлаган. «Бу кечкенә кошлар ничек шулай матур итеп җырлыйлар соң?» – дип баш вата башлаган ул. Һәм беркөнне мондый әмер биргән: «Кем дә кем кошларның ничек һәм ни өчен шулай матур сайрауларын белә, шул җәнлеккә үз телендә сөйләшү мөмкинлеген бирәм!» – дигән. Бу хәбәр ябалакка барып ирешкән. Ул



Ләйсән ҖАББАРОВА, 9 яшь.
Буа, Яңа Тинчәле.



Алия ӘХМӘДУЛЛИНА.
Кукмара, Ядегәр.

көне буе кошларны тыңлый икән дә, төнлә аларның телен өйрәнә икән. Ул кошлар турында бик күп китаплар укыган, аларның яшәү үзенчәлекләрен өйрәнгән һәм мондый нәтиҗәгә килгән: һәр җан иясенең туган җире һәм туган теле бар. Алар аңа бик якын һәм кадерле була. Шушы кадерле нәрсәләрне сакларга кирәк. Аларны онытырга ярамый. Һәр җан иясе туган телендә сөйләшеп, үз туган җирендә яшәгәндә генә бәхетле була. Менә ни өчен кошлар шулай матур сайрый икән! Алар бит үз телләрен онытмаганнар, башка телгә алыштырмаганнар! Алар – бәхетле.

Ябалак бу турыда Аю Әппәскә әйткән, ди. Бу хәбәр Аюга бик ошап бетмәгән. Аның ябалакка ачуы килгән. Шулай да Аю бик гадел икән. Чын дөреслекне аңлатып биргәне өчен, ул ябалакны җибәргән, тик бер шарт куйган. «Син көндез минем күземә күренмә», – дигән. Шуннан соң Ябалак төнлә генә оча торган булган. Ә башка җәнлекләргә Аю Әппәс үз телләрендә сөйләшергә рөхсәт биргән.

Булат ДӘҮЛӘТҖАНОВ, 11 яшь.
Яр Чаллы.

Бәйгегә килгән язмаларның барысын да журнал битләрендә урнаштыру мөмкин эш түгел, әлбәттә. Без инде әкиятләрнең кызык-матур дигәннәренә «Салават күпере»ндә урын бирә килдек. Мәртәбәле жюри, бердәм фикергә килеп, җиңүчеләрне дә ачыклады. Җиңүчеләр күп булмый инде, шулай бит?! Аларга – бүләк, түбәндәге укучыларыбызга исә бездән – ЗУР РӘХМӘТ! Зур рәхмәтебезне менә кемнәргә ирештерәбез:



Илүзә НУРЛЫГАЯНОВА, 6 яшь. Мөслим, Иске Карамалы.

Бәйге тәмам...

Айсылу Хаҗиева (Актаныш, Киров), Илмира Хәлиуллина (Яңа Чишмә, Зирекле), Рәис Җаббаров (Нурлат, Әхмәт), Динә Аскадилова, Рәфия Хаҗиева, Айсылу Шакирҗанова (Саба, Явлаштау), Разил Нуретдинов (Актаныш, Яңа Кормаш), Раилә Сиражетдинова (Менделеев, Бәзәнә), Зөлфәт Мәгъсүмов (Саба, Түбән Утар), Айрат Ханнанов (Азнакай, Сәпәй), Ләйсән Габдуллина (Минзәлә, Гөлек), Шамил һәм Таһир Хәеровлар (Саба, Килдебәк), Рәилә Нәсифуллина, Айнур Гыйльманов (Мөслим, Тойгелде), Булат Ганиуллин (Мамадыш, Ишки), Зөһрә Вилданова (Кукмара, Салтык-Ерыклы), Илнур һәм Илсур Габитовлар (Балык Бистәсе, Түбән Тимерлек), Раил Баһаутдинов, Алсу Сәлахова (Яңа Чишмә, Чаллы Башы), Рәзилә һәм Илсаф Әхмәдуллиннар (Әтнә, Күәм), Алинә Хәсбиуллина (Арча), Илназ Нәбиуллин, Алмир Хәбибуллин (Саба), Айгөл Хәкимуллина (Кукмара, Мәчкәрә), Илшат Гәрәев (Балык Бистәсе, Ямаш), Ләйсән Зарипова (Кукмара), Әлфинә Галимҗанова (Теләче, Кече Мирәтәк), Алисә Рамазанова (Баулы, Татар Кандызы), Марат Әфләтунов (Азнакай, Үчәлле), Илназ Маннанов (Тукай, Биклән), Миләүшә Ризванова (Лениногорск, Яңа Иштирәк), Илсаф Габитов (Буа, Кырык-Садак), Гадел Әхмәтҗанов (Мамадыш, Югары Кыерлы), Зилә, Динә һәм Дәниф Хәмидуллиннар (Арча, Урта Аты), Айзирә Нуриәхмәтова (Мамадыш, Түбән Яке), Айназ Хәмидуллин (Баулы), Тәбрис Мөхетдинов, Гөлия һәм Рәсим Хөснетдиновлар (Әтнә, Югары Сәрдә), Айзат Шакиров (Сарман, Сарысаз), Дилүс Зарипов (Яшел Үзән, Карәтмән), Рамис Таҗиев, Гөлия һәм Илшат Галимовлар (Кукмара, Кыябаш), Энҗе Саттарова (Арча, Югары Пошалым), Гөлназ Гулова (Мамадыш, Урта Тәкәнеш), Алия Нәбиуллина (Азнакай, Катыш), Айназ Фәсхетдинов (Түбән Кама), Лира Мифтахова (Балтач, Карадуган), Марс Гыймадиев (Кукмара, Беренче май), Илүзә Миңнегулова (Питрәч, Кун), Миләүшә Кәшбуллина (Актаныш, Меңнәр), Зөлфия Зарипова (Кама Тамагы, Яңасала), Алмаз Нәҗметдинов (Кукмара, Чишмәбаш), Гөлназ Һидиятова (Арча, Казаклар), Ландыш Солтанова (Мөслим, Тат.Бүләр), Динар Мөхәммәтшин (Әтнә, Бәрәскә), Альмира Дәүләтова (Саба, Сатыш), Илдар Сабиров (Әгерҗе, Тирсә), Нурия Гайсарова (Питрәч, Шәле), Самат Закиров, Нурсил Нурзадин (Балтач, Түнтәр), Аяз Минһаҗев (Актаныш, Чуракай), Илсөя Сабирҗанова, Зөбәрҗәт Мәгъсүмова (Кукмара,



Дилә ИСЛАМОВА, 10 яшь. Актаныш, Иске Сәфәр.



Ләйсән АСАЕВА, 10 яшь.
Зәй, Куш-Елга.



Алия СИБГАТУЛЛИНА, 12 яшь.
Кама Тамагы, Каратал.



Айваз КАЮМОВ, 8 яшь.
Чүпрәле, Яңа Ишле.

Аш-Буҗи), Самат Гафиятов (Аксубай, Яңа Ибрай), Алинә Кәлимуллина (Норлат, Кизләү), Фәнүзә һәм Фәннур Миңнемуллиннар, Наилә һәм Наил Фәйзрахмановлар (Кукмара, Янцыбы), Энҗе Габделхакова (Саба, Иске Мичән), Мария Дмитриева (Чистай, Мөслим), Рузилә Исламова (Азнакай, Татшуган), Айгизә һәм Айсылу Гарәфиевалар (Ютазы, Иске Каразирек), Гүзәл Муллагалиева (Балтач), Ринас Хафизов (Мөслим, Сикия), Гөлүсә Салихова (Арча, Сөрде), Гөлназ Шаһиева, Булат Хафизов, Ләйсән Шаһиева (Казан), Илүзә Гыйльфанова (Зәй, Куш-Елга), Айзат Миннебаев (Теләче, Җәнәй), Илүзә Шәмсетдинова (Лениногорск, Бәкер), Альбина Сазаева (Мамадыш, Юкәче), Габделгазиз Фәттахов (Алабуга), Газиз Һадиев (Балтач, Кариле), Айзил Шәрипов (Биектау, Кече Салабаш), Нурзия Җамалиева (Биектау, Юртыш), Назилә Шәрипова (Кукмара, Зур Кукмара), Айрат Галиев (Теләче, Шәтке), Әдилә һәм Әминә Нигъмәтуллиналар (Кукмара, Ядегәр), Рәдилә Галиәхмәтова (Биектау, Ямаширмә), Айназ Хафизова (Әлмәт, Нәдер), Энҗе Габделәхәтова (Балтач, Борнак), Ләйсән Вилданова (Әлмәт, Елховой), Алия Сибгатуллина (Кама Тамагы, Каратал), Гадел Хөсәенов (Лаеш, Пәрәү), Айнур Шәйдуллин (Биектау, Чувашиле), Гөлфинә Хәбибрахманова (Саба, Олы Арташ), Йолдыз Шаһабиева (Кукмара, Зур Сәрдек), Фирүзә Нурлыгаянова (Мөслим, Иске Карамалы), Люция Әхмәтшина (Әлки, Бибай Чаллы), Рәзил Әгъзәмов (Чирмешән, Түбән Кәминкә), Алсу Гарифуллина (Азнакай), Айгөл Гыйләҗева (Әгерҗе Иж-Бубый), Алмаз Хәертдинов (Арча, Шекә), Диләрә Хөснетдинова (Чистай, Ислəй), Гөлсинә Шиһапова (Яшел Үзән, Югары Урысбага), З.Корманбакиева (Төмән өлкәсе), Гүзәл Вилданова (Түбән Кама, Түбән Чаллы), Салават Нәбиуллин, Әмин Халиков (Сарман, Илексаз), Айгөл Мөхәммәтшина (Арча, Иске Иябаш), Зөлфәт Мостафин (Лениногорск, Кирлегәч), Алисә Мажимова (Баулы, Татар Кандызы), Азамат Хисаметдинов (Буа, Ташкичү), Алия Хаҗинурова (Удмуртия, Завьял), Айгөл Галиуллина (Бөгелмә, Кодаш), Айнур Хәбибуллин (Кукмара, Түбән Арбаш), Ализә Минһаҗева (Актаныш, Тат.Ямалы), Айгөл Сибгатуллина (Чистай, Акбулат), Рафаил Латыйпов (Тәтеш, Кләш), Ренат Алиев (Әлки, Базарлы Матак).

Уңышлар телибез сезгә, дуслар!



Көзге сканворд

- Язын киенә, көзен чишенә
- Язын дөньяга килә, көзен саргаеп үлә
- Орлыгы өчкырлы булган үсемлек
- Орлыгыннан кара икмәк пешерәләр
- Бикле келәт эчендә кара ком
- Бәләкәй генә бөкере бөтен кырны бетерде
- Диңгез түгел – дулкынлана
- Кечкенә генә йорт, эче тулы корт
- Культуралы үсемлекләр үстерелә торган җир мәйданы
- Ашка салсаң, тәм кертә, борынга тисә, төчкертә
- Тун түгел – түгәрәк, күсе түгел – койрыклы
- Башаклы ашлык бөртекләрен тегермәндә тарттырып ясыйлар
- Түгәрәктер, кызылдыр, әчедер дә татлыдыр, йотыйм дисәң ташлыдыр
- Утыра бер ак чүлмәк, өстенә кигән йөз күлмәк
- Ура, суга, җилгәрә, үзе төяп җибәрә
- Каны бар, җаны юк
- Җир астында җиз бүкән
- Зур итеп салынган чүмәлә
- Тимер ат җир сөрә
- Кечкенә генә капчык, эчендә сары балчык
- Өч кат тун кигән – кем салдырса, шул елый
- Ачы тәмле тамыразык
- Эчен ашыйлар, тышын ташлыйлар
- Эче кызыл шикәрле, тышы яшел бәрхетле
- Гәүдәсе бар – җаны юк, үзе эшләпә кигән – башы юк
- Җир астында алтын казык, көзен алырбыз казып

Төзеде Гүзәл СӘЕТОВА





Азалия ШАКИРОВА, 7 яшь.
Сарман, Сарысаз–Тәкермән.

Әнием

И әнием, бу дөньяда
Синсез яши алмас идем.
Син булмасаң, көннәремнең
Яме-тәме булмас иде.

И әнием, и кадерлем,
Син бит минем бердәнберем.
Ай-кояшым, бар җиһаным,
Син бит минем сүнмәс гөлем.

Фәния ВАСИЛОВА.
Балтач, Куныр.

Журналга язылу бәясе – ярты елга 84 сум.

Индексы–73953

Салават күпере

“САЛАВАТ КҮПЕРЕ”–

мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм кече яшьтәге укучылар өчен чыгарыла торган матур, акыллы, юмарт журнал.

Салават күпере

8-9(209–210) — 2007

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТАТМЕДИА» МАССАКУЛӘМ КОММУНИКАЦИЯЛӘР АГЕНТЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: АГЕНТСТВО РТ ПО МАССОВОЙ КОММУНИКАЦИИ «ТАТМЕДИА», ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсеме

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тасләргә бүленде.

«Идел-Пресс» ААҖ.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 3.08.2007 ел. Басарга кул куелды 2.08.2007 ел. Кәгазь форматы 84x108 1/16.

Гарнитура – Прагматика.

Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 9188 данә. Заказ С-916.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хәснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, Н.Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова, А. Вакказов.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

